РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОУСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА УСЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

*423980, РТ, с. Новые Усы, ул. Советская, 30*
*тел. (8-85556) 3-20-30*

---

**№ 2** **Яңа Усы авылы** **«20» февраль 2019 ел**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, "Җирләү һәм күмү эше турында"гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Җирләү һәм күмү эше турында"гы Федераль законны гамәлгә ашыру буенча чаралар турында" гы 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Карарына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең " 2019 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында" гы 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы " Яңа Усы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 44 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1нче һәм 2нче кушымталар нигезендә 5946,47 сум күләмендә расларга һәм 2019 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлеше өчен җаваплылыкны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Мөслим муниципаль районы**
**Яңа Усы авыл җирлеге**
**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазифаларын башкаручы** **Г.С.Романова**

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Яңа Усы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
« 20 » февраль 2019 ел № 2
карарына 1 нче кушымта

**2019 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясе**

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтүнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны әзерләү | 0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3200,38 |
| 3. Мәетне каберлеккә китерү | 873,76 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм гүргә иңдерү) | 1872,33 |
| Барлыгы | 5946,47 |

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Яңа Усы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
« 20 » февраль 2019 ел № 2
карарына 2 нче кушымта

**2019 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясе**

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтүнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны әзерләү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 338,05 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 2862,35 |
| 3. Мәетне каберлеккә китерү | 873,75 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм гүргә иңдерү) | 1872,32 |
| Барлыгы | 5946,47 |